ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 57 от «07» 02 2020 г.

Балигъ булмаган баланы тулысынча
хокукка сәләтле дип игълан итү
(эмансипация) турында карар кабул итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Яңа редакциядә:

1.1. Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. “Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының опекунлык һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында” 2018 елның 28 ноябрендәге 586 санлы карары белән расланган Балигъ булмаган затларны ирекле (тулысынча юридик хокуклы дип белдерү- эмансипация) итү карарын кабул иту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (16 нче санлы кушымта) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын оч көн эчендә интернет мәгълүмати коммуникацион

00010299

челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.02.2020 ел,
57 санлы карарына

1 нчы кушымта

# Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: уналты яшькә җиткән балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары һәм аларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы (алга таба - опека һәм попечительлек органы) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органының урнашу урыны: ТР, Мамадыш ш., М. Җәлил ур., 23/33 йорт, 201 каб.

Опека һәм попечительлек органының эш графигы: шимбә, якшәмбедән кала, көн саен 8 -00 дән 17-00 гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 гә кадәр.

Гаризаларны кабул итү графигы: дүшәмбе, чәршәмбе,пәнҗешәмбе 9-00 дән 17-00 гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 гә кадәр.

Җәмәгать транспортында “Администрация” тукталышына кадәр барырга.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ буенча (яисә ирекле).

Опека һәм попечительлек органының урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат Башкарма комитетның http://www.mamadysh.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырылган.

1.3.2. Белешмә телефоннары: 8(85563)3-31-00, 3-22-39

1.3.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.mamadysh.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы (шәһәр округы) биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

2) «Интернет» челтәре аша:
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www.mamadysh.tatarstan.ru.);
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Башкарма комитетның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, шулай ук электрон почтасы турында мәгълүмат Башкарма комитетның опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырыла http://www.mamadysh.tatarstan.).

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарында мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:
Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ ГК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
Россия Федерациясе Гаилә кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 17, 1755 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – 601 номерлы Президент Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 53, № 7932 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, 4 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2, 70 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3, 212 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба - 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 29 июлендәге № 2-9 карары расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба - БК турында Нигезләмә);
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2008 елның 21 окятбрендәге № 10-22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Башкарма комитеты опека һәм попечительлек органы турында Нигезләмә (алга таба - опека органы (бүлеге) турында Нигезләмә);
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2013 елның 8 ноябрендәге № 6-21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 12 январендәге № 1 карары белән расланган Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр).
1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:
дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең әлеге мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда башкарма хакимият органы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк), башкарма хакимият органының вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмалар, яисә аларның хезмәткәрләре тарафыннан бозылган хокукларын яисә законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турында таләбе;
күпфункцияле үзәк – 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт һәм муниципаль, шул исәптән «бер тәрәзә» принцибы буенча

электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле дәүләт яисә муниципаль учреждениенең (шул исәптән автоном учреждение) оештыру-хокукый рәвешендә төзелгән оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән мөрәҗәгать белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган принцип, ә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар белән үзара хезмәттәшлек, норматив хокукый актлар һәм үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка, күп функцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла;

күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) белешмәләрне кертү өчен нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – ул 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать. Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентка 1, 2 нче кушымталарда китерелгән.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгеле торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү | РФ ГК 27 ст.;<br>№ 8-ТРЗ ТР Законы 5 ст. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге | № 8-ТРЗ ТР Законы 5 ст.; РФ ГК 27 ст. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле (эмансипацияләнгән) дип игълан итү турында карар (күрсәтмә/карар рәвешендә) яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ГК 27 ст.;<br>№ 8-ТРЗ ТР Законы 5 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү | Гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән алып 15 календарь көне.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша, электрон адреска), дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны юллау дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәтен һәм хезмәтләрне күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә | Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлеге:<br>балигъ булмаган баланың гаризасы (1 нче кушымта);<br>гариза - ике ата-ананың да яки балигъ булмаган баланың башка законлы вәкилләренең ризалыгы (2 нче кушымта);<br>балигъ булмаган бала туу турында таныклык күчермәсе (төп нөсхәсен күрсәтеп);<br>балигъ булмаган бала паспортының күчермәсе (төп нөсхәсен күрсәтеп);<br>ата-ананың (законлы вәкилләрнең) шәхесен таныклаучы документлар (төп нөсхәләр һәм күчермәләре);<br>балигъ булмаган баланың хезмәт эшчәнлеген раслаучы документлар (хезмәт килешүе (контракт) яки хезмәт кенәгәсе күчермәләре) (мөрәҗәгать итүче эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнмәгән очракта);<br>атасын яки анасын ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (чикләү), аны хокукка сәләтсез дип тану турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | суд карары күчермәсе (күрсәтелгән шартлар булганда);<br>балигъ булмаган баланың атасы яки анасының үлеме турында таныклык күчермәсе (күрсәтелгән шартлар булганда).<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ала. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Мөрәҗәгать итүче законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган гариза һәм кушып бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырырга (җибәрергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына: | 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булуын яки булмавын раслаучы белешмәләр һәм башка документлар формаларын раслау һәм гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булуын яки булмавын раслаучы белешмәләр һәм башка документларны тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 нче форма буенча туу турында белешмә (Гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>эзләнелә торган ата яки ананың торган урыны билгеле булмау турында эчке эшләр органнары белешмәсе;<br>Шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән балигъ булмаган балага карата шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән).<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары | башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, шул исәптән дәүләт хезмәтләре күрсәткән өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматны тапшыру;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматны бирү | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Документларда алдан әйтелмәгән төзәтмәләр булу.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын тапшыру.<br>3. Мөрәҗәгать итүче яшәмәгән урын буенча мөрәҗәгать итү | 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора: | 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту |

| | | |
|---|---|---|
| | ялгыш (дөрес булмаган) мәгълүматлардан гыйбарәт документлар тапшыру | өчен нигезләрнең тулы исемлеге |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм нигезләре | | кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать тапшырганда, мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты | Чират булган очракта, карар алу өчен кәгазьдә гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән | 601 номерлы РФ Президенты Указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче икенче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле | Хезмәт күрсәтү урыны түбәндәгеләр белән җиһазландырылган:<br>һаваны кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы; | |

| | | |
|---|---|---|
| документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр. | Татарстан Республикасы телекоммуникацияләренең интеграцияләнгән дәүләт системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу урыны һәм алар эчендә уңайлы хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның вакыт буенча озынлыгы күрсәткече, дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүче сайлап алу буенча җирле үзидарә | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булу күрсәткечләре:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге http://www.mamadysh.tatarstan.ru мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга, биналарга аларның керә алу | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарма - боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә Федераль законның 15[1] статьясында каралган берничә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать аша (комплекслы мөрәҗәгать) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге яисә андый мөмкинлек булмау | мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән аларга хезмәтне алуга комачаулаучы башка тоткарлыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән билгеләнә:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен биргәндә чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент нигезендә билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәткәндә консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплексы мөрәҗәгать составында күрсәтелми | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы бүтән таләпләр | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелә.<br>Электрон рәвештә гариза һәм документлар Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юллана, соңыннан карарны алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтү шарт.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә, комплексы мөрәҗәгать буенча гамәлгә ашырылмый | № 63-ФЗ Федераль закон |

**3.** Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

**3.1. Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар алу өчен бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:**

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;
2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү;
3) законлы вәкилгә дәүләт хезмәте алу өчен бәяләмә яисә дәүләт хезмәтеннән баш тарту турында хат әзерләү;
4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;
5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү;
6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче шәхсән, телефон, электрон почта (адрес: http://www.mamadysh.tatarstan.ru) аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы һәм (яки) опека һәм попечительлек органына (алга таба – Бүлек) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен хат белән мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирелә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте алу турында консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк очракта, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә, яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә, яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша заказлы хат аша, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, Бүлеккә гариза бирә (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүне башлап җибәрүче мөрәҗәгатьне бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Гаризаны электрон рәвештә җибәргән очракта - соратылган документларның сканерланган күчермәләре, гаризаны заказлы хат белән җибәргәндә мөрәҗәгать итүче раслаган документлар теркәлә.

3.3.2. Гариза биргәндә белгеч түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

гариза һәм документлар кабул итү;

гариза теркәү;

документларның булу-булмавын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызып ташланган сүзләр һәм алдан әйтелмәгән бүтән төзәтмәләр булмау);

гариза формасы нигезендә, гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүмат (мәгълүмат, белешмәләр) булу-булмауга гариза тутыруның тулылыгын тикшерү.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече тапшыру турында хәбәр белән заказлы почта аша яки гариза бирү ысулына карап, электрон рәвештә карар бирү турында гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итү турындагы тамга белән исемлек күчермәсен бирә һәм мөрәҗәгать итүче гаризасын һәм документларын, карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша Бүлеккә электрон рәвештә җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3 Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү.

Бүлек белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мөрәҗәгатьләрне юллый:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булуын яки булмавын раслаучы белешмәләр һәм башка документлар формаларын раслау һәм гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булуын яки булмавын раслаучы белешмәләр һәм башка документларны тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 нче форма буенча туу турында белешмә бирү турында (Гражданлык хәле актларын теркәү органнарына);

эзләнелә торган ата яки ананың торган урыны билгеле булмау турында эчке эшләр органнары белешмәсен бирү турында;

Шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән балигъ булмаган балага карата шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә) бирү турында.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турында мөрәҗәгать.

3.3.4. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мөрәҗәгатьләр нигезендә соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) билгеләнгән вакытта тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгатьләргә җавап бирү нәтиҗәсе булган мәгълүматлар (документлар) бирү турында юлланган мөрәҗәгатьләр яки соратып алына торган мәгълүматларны бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү.

3.4.1. Бүлек белгече, кергән мәгълүматлар (документлар нигезендә):

тапшырылган документларны тикшерүне гамәлгә ашыра һәм әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын (булмавын) билгели;

рөхсәт бирү турында карар проектын яки, карар бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, карар проектын әзерли;

карар проектын (рөхсәт бирү турында карар кабул ителгән очракта) яки карар бирүдән баш тарту турында хат проектын (рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта) рәсмиләштерә;

рәсмиләштергән карарны теркәп, рөхсәт бирү турында боерык проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат проектын җитәкчегә (аның вәкаләтле затына) кул кую өчен юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җитәкчегә (аның вәкаләтле затына) кул куюга юлланган проектлар.

3.4.2. Җитәкче (аның вәкаләле заты) карарны раслый, карарны имзалый һәм аны мөһер белән таныклый яки карар бирүдән баш тарту турында карарны раслый һәм карар бирүдән баш тарту турында хатны имзалый. Кул куелган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура раслауга проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карар бирү турында расланган карар һәм имзаланган карар яки карар бирүдән баш тарту турында расланган карар һәм карар бирүдән баш тарту турында имзаланган хат.

3.4.3. Бүлек белгече:

карар бирү (карар бирүдән баш тарту) турындагы карарны карарларны теркәү журналында терки;

документлар әйләнеше бүлегенә карар бирүдән баш тарту турында хатны (карар бирүдән баш тарткан очракта) тапшыра;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасын һәм вакытын яки карар бирүдән баш тарту турында хат турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар җитәкче документларны имзалаган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.5.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), бирелгән карарлар журналында кул куйдырып, рәсмиләштерелгән карарны яки карар бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән карар яисә карар бирүдән баш тарту турында бирелгән хат.

3.5.2. Документлар әйләнеше бүлеге белгече баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, карар бирүдән баш тарту турындагы хатны терки һәм аны гаризада күрсәтелгән адрес буенча мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.
Әлеге пунктта билгеләнгән процедура документлар әйләнеше бүлегенә баш тарту турындагы хат кергән вакыттан алып бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында җибәрелгән хат.

3.6. Техник хатаны төзәтү (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Карарны (карар бирүдән баш тарту турындагы хатны) яңадан рәсмиләштерү карарда (карар бирүдән баш тарту турындагы хатта) җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язуларны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Карарны (карар бирүдән баш тарту турындагы хатны) яңадан рәсмиләштерү дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хата булган документны (мондый документ бирелгән очракта) теркәп, теркәлгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.1. Бүлек белгече:

техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итүне һәм аны гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәүне гамәлгә ашыра;

карар проектын (карар бирүдән баш тарту турында хатны) яңадан рәсмиләштерә;

яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын (карар бирүдән баш тарту турында хатны) җитәкчегә кул кую өчен юллый;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, җитәкчегә кул куюга юлланган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.6.2. Җитәкче карарга (карар бирүдән баш тарту турында хатка) кул куя һәм аны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура карар проектын имзалауга җибәргәннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган карар (карар бирүдән баш тарту турында хат).

3.6.3. Бүлек белгече гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә карар турында (карар бирүдән баш тарту турында хат) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән карар (карар бирүдән баш тарту турында хат) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүдән,

дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүдән, опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына карата шикаять булган мөрәҗәгатьләр буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүдән гыйбарәт.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тоту рәвешләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертизаларның нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

билгеләнгән тәртиптә эшләр башкаруга тикшерү үткәрү;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең тәгаен мөрәҗәгате буенча карала ала.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр башкаруны тикшереп тотуны гамәлгә ашыру максатларында опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы белгеч, эшләр башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Белгечләр административ процедураларның вакытларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итә, шулай ук кагыйдә бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризаларын вакытында карауны контрольдә тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла торган) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җавап тота.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль дәүләт хезмәте күрсәткәндә опека һәм попечительлек органы эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. **Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр**

**карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә шикаятьне - Башкарма комитетка, Башкарма комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Муниципаль берәмлек советына бирергә хокуклы.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмалар карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр законда билгеләнгән тәртиптә белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьне теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшырылуы яки башкарылуы каралмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүне таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт

хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны таләп итү.

5.3. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештә бирелә.
Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, http://www.Mamadysh.Ikrayona@tatar.ru) муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын (http://www.mamadysh.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталын кулланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталын яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул ителә ала. 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталын, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителә ала.

5.4. Шикаятьне карау вакыты - аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, әлеге органның, КФҮ, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән басма һәм башка хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.5. Шикаять түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи заты йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәр, КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләре исеме;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр йә мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры, электрон почта адресы (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең,

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүче кылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

## 6. **Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре**

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы органнарга, шул исәптән комплекслы ведомствоара мөрәҗәгать буенча да, ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган квалификацияле санлы имзасының гамәлдә булуын тикшерү;

5) гариза белән документларны Министрлыкка җибәрү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Гариза бирүче КФҮгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, рәвеше һәм башка сораулар буенча мәгълүмат бирә һәм кирәк очракта, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче hh://mfc16.tatarstan.ru КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтен алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә, КФҮгә, КФҮнең читтән торып эш урынына документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон рәвештә алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6.3.2. Гаризалар кабул итүче КФҮ белгече КФҮ эше регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

5.4.1. КФҮ белгече КФҮ эше регламенты нигезендә:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган көчәйтелгән квалификацияле санлы электрон имзасының гамәлдә булуын тикшерә;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы органнарга, шул исәптән комплекслы ведомствоара мөрәҗәгать буенча да, ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыра һәм җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

6.4.2. КФҮ белгече мөрәҗәгатьләргә җаваплар алгач, документлар пакетын формалаштыра һәм аны КФҮ эше регламентында билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар.

6.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

6.5.1. Министрлыктан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе килгән очракта, КФҮ белгече аны билгеләнгән тәртиптә терки, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Министрлыктан документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

6.5.2. КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирә
Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта килгән көнне чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе.

Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

_______________________________________
_______________________________________

________________________________(кемнән),
(Ф. И. А.
тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яши:
_______________________________________
_______________________________________,
(тулы адрес)
телефон: ____________________________
паспорт: ______________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Гариза

Мин, ____________________________________________________________________________
Ф.И.А., туу датасы

Мине түбәндәге нигезләр буенча тулысынча хокукка сәләтле (эмансипацияләнгән) дип игълан итүегезне сорыйм:
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләргә ризалык бирәм.

«___»________________ 20___ ел _________________
(имза)

Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентына 2 нче кушымта

____________________________________________

________________________________(кемнән),

(Ф. И. А. тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яши:

____________________________________________

__________________________________________,

(тулы адрес)

телефон: ___________________________________

паспорт: __________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Гариза

Сорыйм сездән миңа үземнең балигъ ______________________________________________________________________ елда туган ______________________________________________________________________________

(16 яшьтән өлкәнрәк баланың Ф.И.А.)

булмаган балама (тәрбияләнүчегә) түбәндәге нигезләр буенча тулысынча хокукка сәләтле дип (эмансипация) игълан итүгә рөхсәт бирергә:

_________________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
__________________________________________________

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләргә ризалык бирәм.

«___»________________ 20___ ел __________________

(имза)

Балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек җитәкчесе | 8(85563)3-22-39 | Aygyun.Velieva@tatar.ru |
| Бүлек белгече: | 8(85563)3-22-39 | |

Татарстан Республикасы
муниципаль районы (шәһәр округы) советы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8(85563)3-31-00 | http://www. Mamadysh.Ikrayjna.@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 8(85563)3-15-95 | http://www. Mamadysh.Ikrayjna.@tatar.ru |
| Башкарма комитет эшләре идарәчесе | 8(85563)3-19-56 | http://www. Mamadysh.Ikrayjna.@tatar.ru |

Балигъ булмаган баланы
тулысынча хокукка сәләтле дип
игълан итү (эмансипация) турында
карар кабул итү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 4 нче кушымта

ТР
___________________________________
_
муниципаль районы
___________________________________
__
(шәһәр округы
Башкарма комитеты җитәкчесенә

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ________________________________________________________________________________
___________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
________________________________________________________________________________
_
________________________________________________________________________________
_ адресы буенча яшәүче
(индексны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)

________________________________________________________________________________
_
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның исеме, аның сериясе, номеры, бирү датасы,

________________________________________________________________________________
__
документны биргән орган исеме)

__________ ел № ___________________________
карар датасы карар номеры
балигъ булмаган баланы тулысынча хокукка сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул иткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне сорыйм

___________________________________
карар датасы карар номеры

техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алырга риза

______________________________________________________________________________
_ (язмача, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша)

«___» _____________ 20___ ел

____________________ ______________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

(тулы имза)